ГЛАВА АЮСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АЮ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**07.11.2024 ел** **№ 5**

**2025 елда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлегенең Аю торак пунктында гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлеге Уставының 23 статьясына ярашлы рәвештә, «Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлеге муниципаль берәмлек башлыгы

**КАРАР ЧЫГАРА:**

1. 22.11.2024ел 14.00 сәгатькә түбәндәге адрес буенча урнашкан Аю авылы мәдәният йорты бинасында: ТР, Минзәлә муниципаль районы, Аю торак пункты, Үзәк урамы, 53 йорт 2025 елда үзара салымны кертү мәсьәләсе буенча Минзәлә муниципаль районы Аю авыл җирлегенең Аю торак пунктында гражданнар җыены билгеләргә.

2. Гражданнар җыелышына тәкъдим ителгән мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының Аю авыл җирлегенең Аю торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертүгә Сез ризамы?,1.2 төркем инвалидлардан, ветераннардан һәм Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге бүлектә укучы студентлардан, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлардан, күпбалалы гаиләләрдән тыш һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1)Су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм Аю торак пунктында яшәүчеләргә су бирүне (скважиналар өчен тирәнлек насослары сатып алу) тәэмин итү;

3) Аю торак пунктында тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (энергия саклаучы яктырткычларны һәм урам яктырту лампаларын алыштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) ремонтлау;

3)Аю торак пунктында янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (трактор өчен янгынга каршы тагылма җайланма сатып алу һәм җиткерү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3.Әлеге карарны Аю авыл жирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка житкерергә. Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән алып ун көн эчендә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

5.Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Минзәлә муниципаль районы
Аю авыл жирлеге башлыгы _______________ А.М.Галимов